Апас муниципаль районы «Борнаш урта гомуми белеем бирү мәктәбе”

Гомуми белеем муниципаль бюджет учреждениесе

**Фәнни- эзләнү эше:**

# “ТУГАН ЯГЫМ КҮЛЛӘРЕ”

Эшләде: 9 сыйныф укучысы
Җәләлиева Исламия Илсур кызы .
Фәнни җитәкче
Биология һәм география фәне
укытучысы Сибгатуллина Лилия Галихан кызы.

2020

**Эчтәлек**

Кереш..............................................................................................3

Төп өлеш

1. Районның күлләре..............................................................................4
2. Туган як күлләре атамалары тарихы.....................................................5- 6

Йомгаклау..........................................................................................6-7

Кулланылган материал

## Кереш.

**Фәнни эшемнең темасы:** Туган ягым күлләре.

**Максатым**- Туган ягымның күл атамалары тарихын өйрәнү.

**Бурычлар:** Үзебезнең авыл җирлегендә ничә буа- күл булуын ачыклау;

Күлләрнең нигә шундый исем- атама алулары турында материал туплау, аларны саклап калуның әһәмиятен билгеләү.

Фәнни- тикшерену эшемнең **төп объекты-** Борнаш-Әлмәндәр авыллары арасына урнашкан күлләр.

Теманың **актуаль**леге шунда: туган төбәгемнең буа-күлләр тарихын туплау һәм өйрәнү туган ягымны, аның кешеләрен яхшы белергә ярдәм итте.

**Фәнни-тикшерену эшенең гипотезасы:** Безнеңчә, авылыбызның күлләренә бездән ярдәм кирәк.

**Фәнни-тикшерену эшенең алымнары:**

1.Күзәтү.

2. Сораштыру.

4. “География һәм экология Апастовского района”, “Апасым- гомер бишеге” китапларындагы бастырылган мәгълүматлар белән танышу.

**Төп өлеш.**

## 1. Районның күлләре

**Тарихны Римнан түгел үзең торган нигездән эзләргә кирәк.**

Апас районында күлләрнең кызыклы бер тарихы бар. Гомумән, күлләр кешеләр тормышында әһәмиятле урын тоталар. Борынгы заманнарда бер урыннан икенче урынга нindидер сәбәпләр аркасында күчкәндә кешеләр авыл тирәсендә яки уртасында чишмәләр, елгалар белән бергә күлләрнең дә булуын телиләр.

Тарихи яктан ясалма күлләрне ике төркемгә бүлеп була. Беренчеләре- 1910-1912 елларда патша галиҗанәпләре әмере буенча казытылган күлләр. Ул чорда алар кул көче белән казылган.

Икенчеләре- инешле- чишмәле чокырларны буып ясалган буа- күлләр (плотиналар).

Экология табигый системалар АН РТ институты мәгълүматы буенча, Апас районында 171 күл булуы турында әйтелә.

## 2. Туган як күлләренең атамалары тарихы

Әлмәндәр, Борнаш авыллар булып оешкач урманнарны кисә-кисә сөрү җирләре, басулар күбәйгән. Ул вакытта күл,елга,чокыр,аланлыклар төрле кеше исемнәре белән аталганнар.Шулай да табигый күренешләр белән дә исемләнгәннәр:

**Шәм күле-** дигән күл ул вакытта бик куе урман эчендә мул сулы, камышлар, башка су үсемлекләре белән чолганып торган, су кошлары яшәгән зур күл булган.Ул авылдан 3 км ераклыкта урнашкан.

**Имән күле-** авылның көньяк-көнбатышында,300 м ераклыкта гына.Аның тирәсендә имән агачлары күп булган.

Шәм күленнән көньяк-көнбатышка таба 2 км ераклыкта **Якты күл** исемле күл бар.Ул басу чигендә,тирә-ягына караганда бераз күтәренке урында торганда.

Әлмәндәр басуының көньяк чигендә 6 км ераклыкта **Мүкле күл** бар.Аның өсте,күбрәк олеше,мүк белән капланган,сыгылып торган сазлык булган.

Авылның көньяк көнчыгышында 1,5 км ераклыкта **Чи-чи** түбәнлеге бар.Аның буе көньяктан-тоньякка таба таба 2 кмга сузыла.Түбәнлектә тир-ягында,уртасында күп чыганаклар,чишмәләр булган.Бу урын бик юеш, сазлыклырак булган,һәрвакыт чи,чеп чи,юеш торган. Шуннан Чи-чи исемле булып калган.

Чүп һәм Шәм күлләре янында гына **Таллык күл** исеме алган күл бар. Мөртәс, Шәмүк, Иман күлләре атамалары шушы бабайлар исеменнән алынган. **Бакалы күл** кипкән, ләкин яз көннәрендә аның урынында су җыелып тора. Бер-берενә якын гына урнашкан ике күлне **Ябәш күле** дип йөртәләр. Батырша чыгары күле Инешкә килеп кушыла. **Сыгылмалы күл** атамасы бу җир асты сулары белән тоташуын күрсәтә. Аксакаллар сөйләве буенча бу күл суыннан пароход борыны чыккан, дип сөйлиләр.

Чишмәләр һәр авылның ямен, матурлыгын арттыралар. Авылда һәм авыл тирә-юнендә чишмәләр байтак. Кизләү чишмәләренең сулары тәмле,тирәләре каралган. Авыл халкы өчен бу урын изге,өченче хаҗ булып тора: Мәккә, Шәһри болгар һәм **Рыс кизләве**. Корылык елларда монда килеп, Алладан яңгыр сорап намаз укыганнар. Киткән, кайткан кешеләр барып суын эчкәннәр. Күлмәк җебен алып чишмә суына салып агызганнар. Солдатка алынасы егетләр китәсе көнне кызлар биргән кулъяулыкларын тал агачына бәйләп калдырганнар.Бабайлар сөйләве буенча Рыс кизләве каен тузыннан эшләнгән “тырыс” сүзеннән килеп чыккан (тырыс ул каен тузыннан эшләнгән чиләк)

1967 елда колхоз һәм авыл советы тарафыннан чишмә рәшәткә белән әйләндереп алына. 2017 елда Халиков Кадыйр Габделхәй улы ярдәме белән (иганәче спонсор) Тигәнәле (хәзерге Ленин урамы) башына Рыс кизләвеннән су китерелә. Чи-чи елгасы  да Рыс кизләвеннән башлана.

## Йомгаклау.

“Уткәнен белмәгән, киләчәген белмәс”,- дигән бик гыйбрәтле мәкаль бар. Әйе, үткәннәрне кайгырту- киләчәгебез турында кайгырту да ул. Мин дә шушы кечкенә генә фәнни хезмәтемдә авылыбызның горурлыгы булган күлләребез тарихын яктыртырга тырыштым. Эзләнү эшен туплаганда кызыклы очрашулар булды, файдалы сөйләшуләр алып барылды, бастырылган китаплардан  бик күп мәгълүмат алдым. Туган йортын,туган ягын, аның табигатен чын күңелдән яраткан кеше генә Ватанын ярата, аны саклау өчен үз- үзен  аямыйча көрәшкә күтәрелә. Ә Ватанны чишмәләрдән, елга- күлләрдән башка күз алдына китереп булмый.

Без, яшь буын, чишмә- күлләребез серен беләбезме соң? Белмибез икән, әти- әниләрдән, әби- бабайлардан аларның тарихын сорарга ашыгыйк. Чишмә- күлләребез сере- халкыбыз тарихы бит ул. Соңгы елларда кайбер күлләрнең

төбе лəмнəн чистартылып, күл кырыйлары корыган агачлардан, чүплəрəн арындырылды. Бу эштə авыл халкы актив катнашты.

Кеше җирдə ни өчен яши? Үзенең кыска гына гомере эчендə ул барысына да өлгерергə, барын да танырга, белергə, үзе эшлəп калырга, сөенергə, шатланырга, кайгы-хəсрəтне җиңеп чыгарга һəм, иң мөһиме, үзе турында килəчəк буынга якты истəлек калдырырга тиеш. Минем бу хезмəтем туган як күллəре тарихын килəчəк буынга җиткерүгə күпмедер дəрəҗəдə өлеш кертсə, үземне максатыма ирештем дип санар идем.

**Фəнни-тикшеренүэшенең нəтиҗəлəре:**

Безнең күзəтүлəрдəн, сораштырулардан, тикшеренүлəрдəн күренгəнчə без авылыбыз күллəре турында күп кенə материал таптык, аларны өйрəндек, җирлегебездəге күллəрнең торышы бик үк яхшы түгеллеге ачыкланды, күпчелек күллəргə безнең ярдəм кирəк. Без күллəребезне өйрəнүебезне тагын да дəвам итəчəкбез. Барлык күллəрне өйрəнеп, алар турында җитəрлек материал туплагач брошюра яки китап итеп бастырып чыгарырга да хыялыбыз бар. Ə иңмөһиме – сулыкларны саклау буенча эшне җəелдерергə уйлыйбыз! Аларны чистарту кирəк. Авыл халкына да шушы телəкне җиткерəчəкбез.

## Кулланылган материал


1. Апасым- гомер бишегем. Автор һәм китапны төзүче Х.А. Гайнуллин. – Казан, ДУП ПНК “Идел- Пресс, 2000.
2. География и экология Апстовского района. Р.Г. Ногманов.- ОАО “Татмедиа” “Редакция газеты “Йолдыз”, 2011.
3. “Йолдыз” газетасы статьялары- 2009
4. Интернет ресурслар.